**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

**15 ноябрь 2023 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2023 елның 15 ноябрендә узган: «2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;

Әхмәт авылында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 96 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 61 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 57 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 4 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Әхмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;

Әхмәт авылында урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлегенең Әхмәт авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Г.Н. Лизратова

Әхмәт авыл җирлеге башлыгы: Г.Н. Лизратова